РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ГЛАВА**
**Кирельского сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**БАШЛЫГЫ**
**Кирельского сельского поселения**

Улица Гагарина, дом №1, Камско-Устьинского района, 422827, Республика Татарстан
Телефон 8 (277) -367-45.

Гагарина Ур, Кама-Тамагы район, 422827, Республика Татарстан
Телефон 8 (277)- 367-45.

# КАРАР

**2020 елның 10 ноябре** **№3**

**«Гражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кирельский авыл җирлегенең Кирельский авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельский авыл җирлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

***1.*** Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кирельский авыл җирлегенең Кирельский авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2020 елның 28 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка билгеләргә.

***2.*** Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельский авыл җирлегенең Кирельский авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2020 елның 28 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3. Гражданнар җыенына куела торган мәсьәләне расларга:

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельский авыл җирлегенең Кирельский авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2021 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- авыл эчендәге һәм урам ара юлларны төзекләндерү һәм карап тоту

(шартнамә буенча эшләр өчен түләү, вак таш сатып алу, кайтарту , вак таш җәю, тигезләү);

- җәйге-көзге чорда чүп үләннәрне чаптыру (килешү буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

-юлларны кышкы тәртиптә тоту (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу).

“РИЗА” “КАРШЫ” .

4. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән игълан итәргә:
   - ТР, Кама Тамагы районы, Кирельский ав., Гагарин ур., 1 йорт (административ бина);
   - ТР, Кама Тамагы районы, Кирельский авылы, Гагарин ур. 14 йорт (“Раифа” кибете).
   - ТР, Кама Тамагы районы, Кирельский авылы, Түбән ур.,6 йорт (китапханә);
   шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында ,кабул ителгән көннән алып 3 көн эчендә урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районының Кирельский авыл
җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы Ф.Я.Зиннәтуллин